ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«18» март 2025 ел** **№ 250**

**“2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллануны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш” муниципаль программасын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллануны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш” муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Муниципаль программаның төп чараларын башкаручы оешмаларга һәм учреждениеләргә муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

4. Әлеге муниципаль программаны гамәлгә ашыруны тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

## “2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллануны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш” муниципаль программасы

## Муниципаль программа паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа исеме | “2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллануны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш” муниципаль программасы (алга таба - Программа). |
| Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге “2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясе халкы арасында алкоголь продукциясен чиктән тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру Концепциясе турында” 2128-р номерлы күрсәтмәсе;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 16.03.2017 № 150 карары редакциясендә) “2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш” дәүләт программасының “2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасында алкоголь продукциясен чиктән тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау” ярдәмче программасы;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 1 июлендәге “2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү “дәүләт программасын раслау турында” 461 номерлы карары;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 августындагы “2014-2018 елларга Татарстан Республикасы оешмаларында эшләүче яшьләрнең потенциалын гамәлгә ашыру концепциясен раслау турында” 604 номерлы карары. |
| Муниципаль программаның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Муниципаль программаның төп максатлары | - алкоголь продукциясен куллану күләмнәрен киметү;<br>- халыкның төрле катламнары арасында алкоголь продукциясен чамадан тыш куллануны һәм алкоголизмны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- көнкүрештә агуланулар, шул исәптән алкоголь белән агуланулар аркасында район халкының үлү очраклары киму;<br>- район халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм раслау |
| Муниципаль программаның төп бурычлары | - алкоголь продукциясен куллануның гомуми дәрәҗәсен киметү;<br>- район халкында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;<br>- алкогольгә бәйлелеге булган затларга наркологик медицина ярдәме күрсәтү һәм социаль реабилитацияләү системасын |

| | |
|---|---|
| | камилләштерү;<br>- исерек хәлдә кылынган җинаятьләр санын киметү. |
| Муниципаль программаның төп чараларын башкаручылар | “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МУ;<br>Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” МУ;<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге;<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (килешү буенча);<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>“Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау хезмәтенең Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча);<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органы (килешү буенча);<br>“ТАТМЕДИА” АҖнең “Арча-Информ” филиалы (килешү буенча). |
| Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2025-2027 еллар |
| Муниципаль программаның максатына ирешү Индикаторлары | Спиртлы продукция белән кискен агуланулар санының кимүе (10 мең кешегә 0 кеше);<br>алкоголь продукциясе белән агулану нәтиҗәсендә халыкның үлү дәрәҗәсе кимү (10 мең кешегә 0 кеше). |
| Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны гамәлгә ашыру өчен Арча муниципаль районы бюджетыннан максатчан акча бүлеп бирү каралмаган. |

## 1 бүлек. ПРОБЛЕМАНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ

### 1.1 Программаның гомуми нигезләмәләре

2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкы арасында алкоголь продукциясен куллану күләмнәрен киметү, алкоголь продукциясен чиктән тыш куллануны һәм алкоголизмны профилактикалау сәясәтен гамәлгә ашыру халыкның алкоголь продукциясен, шул исәптән аз алкогольле эчемлекләрне, сыраны һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне куллану күләмнәрен киметүгә юнәлдерелгән (алга таба - алкогольле продукция), муниципаль районда демографик хәлне яхшырту, халыкның гомер озынлыгын арттыру, үлүчеләр санын киметү, сәламәт яшәү рәвешенә стимуллар булдыру.

Әлеге Программа 2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкы арасында алкоголь продукциясен куллану күләмен киметү, алкоголь продукциясен чиктән тыш куллануны һәм алкоголизмны профилактикалау сәясәтен гамәлгә ашыруның максатларын, бурычларын һәм механизмнарын билгели.

### 1.2 Муниципаль программа проблемасына характеристика

Алкоголь продукциясен чиктән тыш куллану районда демографик һәм социаль проблемалар туплануның төп сәбәпләренең берсе булды.

Алкоголь продукциясен чиктән тыш күп куллану кешеләрнең вакытыннан алда үлүенә китерә һәм җәмгыятьнең билгеле бер өлешендәге социаль деградациянең төп сәбәпләренең берсе булып тора, бу җинаятьчелек һәм көч куллануның үсүендә, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар санының артуында чагыла, халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый, гражданнар арасында инвалидлык очраклары санын арттыра.

Район халкының югары дәрәҗәдә алкоголь куллануы проблемасы тармакара һәм ведомствоара хезмәттәшлек позициясеннән хәл ителергә тиеш. Алкоголь продукциясен куллану масштабларын киметү район халкының сәламәтлеген һәм хезмәт потенциалын саклау өчен бик мөһим.

Соңгы елларда көнкүрештә агулану очраклары теркәлмәгән.

Наркология кабинетында диспансер исәбендә торалар:

| Диагноз | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлкәннәр | яшүсмер | өлкәннәр | яшүсмер | өлкәннәр | яшүсмер |
| Хроник алкоголизм | 211 | 0 | 250 | 0 | 226 | 0 |
| Спиртлы эчемлекләр кулланучылар | 0 | 0 | 5 | 0 | 5 | 1 |

“Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУның терапия бүлегенә алкогольнең кискен токсик тәэсире диагнозы белән хастаханәгә салынганнар:

| 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | |
|---|---|---|---|---|---|
| өлкәннәр | яшүсмер | өлкәннәр | яшүсмер | өлкәннәр | яшүсмер |
| 0 | 0 | 0 | 0 | 1 | 0 |

“Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда 2022-2024 елларда алкоголь интоксикациясеннән вафат булучылар: 2022 - 0, 2023-0, 2024 -1.

2024 елның 12 ае нәтиҗәләре буенча 415 җинаять теркәлгән, бу УЕШЧ белән чагыштырганда 12,5% ка күбрәк (369).

Җәмәгать урыннарында 53 җинаять теркәлгән, бу УЕШЧ (62) белән чагыштырганда 14,5% ка кимрәк (ТР буенча 20,7%), шул исәптән исерек хәлдә - 0.

Урамнарда 44 җинаять теркәлгән, бу УЕШЧ (26) (ТР буенча 17,1%) белән чагыштырганда 69,2% ка күбрәк, шул исәптән исерек хәлдә - 10 (УЕШЧ – 14).

2024 елның хисап чорында 1 граждан спиртлы эчемлекләр эчкән һәм җәмәгать урыннарында исерек хәлдә күренгән өчен җәлеп ителгән (УЕШЧ - 0).

Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөргән өчен (РФ Административ хокук бозулар кодексының 20.21 маддәсе) 36 административ беркетмә төзелгән, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 56,5%ка күбрәк. (УЕШЧ - 23).

2024 елда 33 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, бу УЕШЧ (35) белән чагыштырганда 5,7% ка кимрәк (ТР буенча 2,5 %). Шулардан җәяүлеләр гаебе белән - 1, УЕШЧ гаебе белән - 3. Исерек хәлдә йөртүчеләр гаебе белән юл – транспорт һәлакәтләре саны кимеде - 1, УЕШЧ-3 (ТР буенча - 3,6 %).

Алкоголь куллануның яшь чикләренең тагын да кимүе, балалар һәм яшүсмерләр арасында спиртлы эчемлекләрне зарарлы куллануның һәм алкоголизмның артуы аеруча борчу тудыра. Җитди куркыныч үсеп килүче буынның сәламәтлегенә, әхлакый тәрбиясенә, интеллектуаль һәм физик үсешенә янаячак.

Китерелгән статистик мәгълүматлар әлеге программаның максатларын һәм бурычларын, шулай ук кабул итү кирәклеген билгели.

## 1.3 Муниципаль программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максатлары:

- алкоголь продукциясен куллану күләмнәрен киметү;
- халыкның төрле катламнары арасында алкоголь продукциясен чамадан тыш куллануны һәм алкоголизмны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру;
- көнкүрештә агуланулар, шул исәптән алкоголь белән агуланулар аркасында район халкының үлү очраклары кимү;
- район халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм раслау.

Программаның бурычлары:

- алкоголь продукциясен куллануның гомуми дәрәҗәсен киметү;
- район халкында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;
- алкогольгә бәйлелеге булган затларга наркологик медицина ярдәме күрсәтү һәм социаль реабилитацияләү системасын камилләштерү;
- исерек хәлдә кылынган җинаятьләр санын киметү.

Программаның ведомствоара характеры һәр учреждениегә һәм оешмага аның функциональ үзенчәлеге нигезендә бурычлар куюга юнәлдерелгән:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының алкоголизмны профилактикалау өлкәсендә “Мәгариф идарәсе”:

- балаларда һәм яшүсмерләрдә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда, алкогольгә каршы тәрбия системасын камилләштерүдә мәгариф оешмаларының ролен арттырырга;
- гомуми белем бирү оешмаларында даими рәвештә алкогольгә каршы тематикадагы кинолекторийлар, лекцияләр, әңгәмәләр уздыруны тәэмин итәргә;
- Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә һәм эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсендә профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнарны өстәмә белем бирү системасына массакүләм җәлеп итү эшен оештырырга;
- яшүсмерләр-яшьләр арасында алкоголизм таралу процессларын өйрәнү һәм анализлау максатында укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә аноним анкета бирү практикасын дәвам итәргә;

2) “Татмедиа” АҖнең “Арск-информ” филиалына алкоголизмны профилактикалау өлкәсендә муниципаль һәм иҗтимагый оешмаларны җәлеп итеп, алкогольнең сәламәтлеккә, гаилә иминлегенә һәм кешенең рухи бөтенлегенә китергән зыяны, алкогольгә каршы сәясәт чаралары турында халыкны мәгълүматлаштыруга юнәлдерелгән даими нигездә мәгълүмати-пропаганда эше алып баруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә;

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлегенә Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге белән берлектә (килешү буенча) балигъ булмаганнарга спиртлы эчемлекләр һәм сыра сату фактларын ачыклау һәм булдырмау эшен көчәйтергә;

4) алкоголизмны профилактикалау өлкәсендә “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУна тәкъдим итәргә:

- билгеләнгән тәртиптә алкогольне чиктән тыш күп куллануга, наркотик матдәләрне медицинадан тыш куллануга һәм токсикоманиягә бирелүчән затларны ачыклау һәм исәпкә алу чараларын күрергә;
- алкоголизмнан интегүче затларга медицина һәм реабилитация ярдәмен оештыруның яңа формаларын кертүгә ярдәм итәргә;
- халыкның сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны тәэмин итәргә;

5) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә алкоголизмны профилактикалау өлкәсендә:

- балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында алкоголизм таралу проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатыннан иҗтимагый акцияләр уздырырга;

- гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның, 35 яшькә кадәрге яшьләрнең көнкүрешен, ялын, спортын һәм туризмын тәэмин итәргә;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы бүлеге белән берлектә (килешү буенча) балигъ булмаганнарга алкоголь продукциясен законсыз сату урыннарын ачыклау буенча рейдлар үткәрергә;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе белән берлектә район халкында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, эчкечелекне һәм алкоголизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

- гражданнарга аларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә, Ватан һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләренә тартуда, көнкүреш, ял, спорт һәм туризмны тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;

6) Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенә алкоголизмны профилактикалау өлкәсендә тәкъдим Итәргә:

- контрафакт һәм халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган алкоголь продукциясен әйләнештән алу, шулай ук балигъ булмаганнарга алкогольле һәм спиртлы продукция сату фактларын булдырмау буенча оператив-профилактик чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

- өйдә җитештерелгән каты спиртлы эчемлекләрне сату, шулай ук сату максатында әзерләү яки саклау фактларын ачыклау эшчәнлеген активлаштырырга;

- наркоманияне һәм алкоголизмны профилактикалауга, яшьләргә әхлакый тәрбия бирүгә аерым игътибар биреп, районның гомуми белем бирү оешмаларындагы чараларны системалаштырырга.

## 2 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

| Муниципаль программаны гамәлгә ашыру срогы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыру этаплары | Муниципаль программа этабын гамәлгә ашыруның турыдан-туры нәтиҗәләре |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2025-2027 еллар | Алкогольгә каршы тәрбия | Яшүсмерләрдә әхлакый категорияләр, җәмгыять әхлагы һәм андагы мөнәсәбәтләр нормалары турында күзаллау системасы формалаштыру |
| | Мәгълүмати-пропаганда эше | Алкоголь куллануның зыяны һәм нәтиҗәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү, алкоголь куллануга психологик тотрыклылык булдыру, «эчкечелекне» һәм алкогольгә бәйле үз-үзеңне тотышыңны кисәтү, хокук бозулар дәрәҗәсен киметү. |
| | Балигъ булмаганнарга спиртлы эчемлекләр һәм сыра сату фактларын ачыклау һәм аларга чик кую | Алкогольнең ныгып җитмәгән яшүсмер организмына китергән зыянын булдырмау. |
| | Алкоголизмнан интегүче затларга медицина һәм реабилитация ярдәмен ачыклау, исәпкә алу, оештыру | Алкогольгә бәйле гражданнар санының кимүе. |
| | Район халкында сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру | Зарарлы гадәтләрдән баш тартуны стимуллаштыру. |
| | Контрафакт һәм халык тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган алкоголь продукциясен әйләнештән алу буенча оператив-профилактик чаралар | Спиртлы продукция белән кискен агуланулар санының, алкоголь продукциясе белән интоксикация нәтиҗәсендә халыкның үлү дәрәҗәсенең кимүе. |

## 3 бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ

| N п/п | Чараның исеме | Үтәү сроклары | Чараларны башкаручылар | Район бюджеты акчалары исәбеннән финанслау күләме (еллар буенча), мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Максатлар: алкоголь продукциясен куллану күләмнәрен киметү; халыкның төрле катламнары арасында алкоголь продукциясен чиктән тыш куллануны һәм алкоголизмны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру; көнкүреш агуланулары, шул исәптән алкоголь белән агуланулар аркасында район халкының үлү очракларын киметү; район халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм раслау. | | | | | | |
| 1 бурыч: Алкоголь продукциясен куллануның гомуми дәрәҗәсен киметү | | | | | | |
| 1.1 | Алкоголь продукциясен чиктән тыш куллануның зарарлы нәтиҗәләре турында мәгълүмати материаллар әзерләү һәм тарату | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Арча үзәк хастаханәсе” ДАСУ (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.2 | Эчкечелек һәм алкоголизмның зыяны турында социаль юнәлештәге пропаганда материалларын бастырып чыгару | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Татмедиа” АҖнең “Арск-информ” филиалы (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.3 | Эчкечелекне һәм алкоголизмны профилактикалау буенча агарту чаралары (“түгәрәк өстәлләр”, матбугат конференцияләре, сәламәтлек көннәре һ. б.) үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Арча үзәк хастаханәсе” ДАСУ (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.4 | Фальсификацияләнгән алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз җитештерү урыннарын ачыклау | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органы (килешү буенча), районның шәһәр һәм авыл җирлекләре (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.5 | Җәмәгать урыннарында, бигрәк тә ял итү һәм спорт чараларын үткәрү урыннарында алкоголь | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | продукциясен һәм балигъ булмаганнарга сыра сатуны һәм алкоголь продукциясен эчүне туктату буенча махсус чаралар үткәрү | | (килешү буенча), Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органы (килешү буенча), КДН һәм ЗП (килешү буенча) | | | |
| 1.6 | Балалар һәм яшүсмерләрнең җәйге ялын оештыручы учреждениеләрнең эш планнарына алкогольгә каршы юнәлештәге профилактик чаралар кертү | Ел саен | "Мәгариф идарәсе" МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 1.7 | "Куркыныч тудырган төркемнәр"дәге укучыларны тәрбияләү мәсьәләләре буенча педагогик советлар үткәрү, имин булмаган гаиләләр белән эшләү | III квартал ел саен | "Мәгариф идарәсе" МУ, гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.8 | Массакүләм мәгълүмат чаралары, сәламәт бала тәрбияләү кабинетлары һәм балалар дәвалау-профилактика учреждениеләренең медик-социаль ярдәм кабинетлары аша сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, "куркыныч тудыручы төркемнәр" арасында көнкүреш агулануларын профилактикалау эшен активлаштыру | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | "Арча үзәк хастаханәсе" ДАСУ (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.9 | Алкоголизмны профилактикалау буенча мәгълүмати-аңлату эше, ялгыз яшәүче 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга, I һәм II төркем инвалидларга, күпбалалы гаиләләргә һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләргә йөргәндә истәлекләр, буклетлар тарату | Ярты елга 1 тапкыр | Районның шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 2 бурыч: Район халкында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру | | | | | | |
| 2.1 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, гаилә институтын үстерүгә юнәлдерелгән мәкаләләрне | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | "Татмедиа" АҖнең "Арск-информ" филиалы (килешү буенча) | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару | | | | | |
| 2.2 | Алкогольле эчемлекләр куллануны беренчел профилактикалау үзенчәлекләре буенча гомуми белем бирү оешмалары өчен методик тәкъдимнәр эшләү | 2025 елның II кварталы | “Мәгариф идарәсе” МУ | - | - | - |
| 2.3 | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру проблемалары буенча педагогик хезмәткәрләр өчен семинарлар оештыру | IV квартал, ел саен | “Мәгариф идарәсе” МУ | - | - | - |
| 2.4 | Авыр тормыш хәлендә калган, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә исәптә торучы балигъ булмаганнар өчен Социомәдәни, спорт - савыктыру чараларын оештыру һәм үткәрү | III квартал, ел саен | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.5 | Гомуми белем бирү оешмаларында гаилә спорт конкурсларын һәм ял көненең гаилә турларын оештыру һәм үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.6 | Яшьләр һәм өлкәннәр өчен алкоголь продукциясен куллану традициясен бетерә торган ял һәм ял итүнең яңа төрләрен оештыру | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.7 | Районда алкоголь продукциясен чиктән тыш куллануны профилактикалауга һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән халыкның киң катламнарын колачлаган спорт-массакүләм, физкультура чаралары үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.8 | Китапханәләр базасында асоциаль тәртипне профилактикалауга һәм сәламәт яшәү рәвешенә мотивация формалаштыруга юнәлдерелгән китап күргәзмәләре оештыру | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәдәният идарәсе” МУ, “Арча үзәк китапханәләр системасы” МБУ | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.9 | Район китапханәләренең китап фондын сәламәт яшәү рәвеше әдәбияты белән тулыландыру | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәдәният идарәсе” МУ, “Арча үзәк китапханәләр системасы” МБУ | - | - | - |
| 2.10 | “Алкогольдән баш тарту көне”, “Сәламәт һәм көчле булырга телим”, “Аек гаилә - сәламәт балалар” акцияләрен оештыру | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ТР МТЗ һәм СЗның Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.11 | “Сәламәт яшәү рәвеше өчен” агитбригадалар конкурсын оештыру һәм уздыру | II-III кварталлар, ел саен | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.12 | “Мин сәламәт яшәү рәвешен сайлыйм” плакатлар һәм стена газеталары конкурсын оештыру һәм үткәрү | II квартал, ел саен | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.13 | Сәүдә оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре өчен алкоголь продукциясе әйләнеше өлкәсендәге законнарның яңа таләпләрен аңлату буенча семинарлар оештыру һәм үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | АМР БК икътисад һәм финанслар бүлеге | - | - | - |
| 2.14 | “Укучылар күзлегеннән яшьләр проблемалары” фәнни-гамәли конференциясен үткәрү | IV квартал, ел саен | “Мәгариф идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.15 | Мәктәп яшүсмерләренең алкоголизм мәсьәләләре буенча мәгълүматлылык дәрәҗәсенә анкета үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.16 | Район китапханәләрендә, мәктәпләрендә алкоголизмны профилактикалау проблемалары буенча семинарлар, лекцияләр, кинокүзәтүләр, видеокүзәтүләр, класс сәгатьләре үткәрү: “Сыраның зыяны һәм сыралы алкоголизм”; “Алкоголь һәм | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, “Арча үзәк хастаханәсе” ДАСУ (килешү буенча) | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | киләчәккә планнар”,<br>“Алкогольгә “юк” дип әйт!” | | | | | |
| 2.17 | Бөтендөнья аеклык һәм алкоголизмга каршы көрәш көненә багышланган “Минем сәламәтлегем - Милләт сәламәтлеге” ял чарасы, “Алкоголь өстеннән Суд!” театральләштерелгән тамаша | IV квартал, ел саен | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.18 | Велоузыш | II квартал, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.19 | Район үзәк хастаханәсе белгечләрен, хокук саклау органнары хезмәткәрләрен, психологларны чакырып, ата-аналарны һәм яшүсмерләрне җәлеп итеп, мәгариф учреждениеләрендә әңгәмәләр, очрашулар, “түгәрәк өстәлләр” оештырырга | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.20 | Куркыныч тудыручы төркемдәге халык, алкоголь кулланучы яшь гаиләләр белән индивидуаль эш алып бару (консультацияләр, әңгәмәләр, тренинглар һ. б.) | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе, ТР ХЭТИ һәм СЯМның Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.21 | Беренчел профилактика һәм психоактив матдәләргә бәйлелекне иртә ачыклау буенча тематик укыту семинарларының даими эшләүче циклын үткәрү:<br>- мәгариф оешмаларындагы психологлар, педагоглар һәм ата-аналар өчен;<br>- медицина хезмәткәрләре өчен;<br>- укучыларның төрле яшьтәге төркемнәре өчен. | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ (килешү буенча), ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.22 | Балигъ булмаганнар, ата - аналар, мәгариф оешмалары, яшүсмерләр берләшмәләре хезмәткәрләре өчен мәгълүмати-пропаганда һәм методик материаллар (листовкалар, брошюралар, буклетлар) әзерләү, алкоголизмга каршы | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе”, “мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениеләре, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, гомуми белем бирү учреждениеләре | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | юнәлдерелгән тематикалы плакатлар сатып алу | | (килешү буенча), “Татмедиа” АҖнең “Арск-Информ” филиалы (килешү буенча) | | | |
| 2.23 | Баннерлар бастыру:<br>- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм алкогольгә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру буенча социаль реклама | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | - | - | - |
| 2.24 | Өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлеге карамагындагылар өчен сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча акцияләр | 2025-2027 еллар (квартал саен) | ТР ХХЭТИ һәм СЯМның Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.25 | “Өлкән кеше өчен куркынычсызлык мәктәбе” технологиясе кысаларында өйдә социаль хезмәтләр алучылар белән индивидуаль әңгәмә үткәрү | ай саен | ТР ХХЭТИ һәм СЯМның Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 2.26 | Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне сәламәт яшәү рәвеше алып баруга җәлеп итү гамәлләре | ай саен | ТР ХХЭТИ һәм СЯМның Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 3 бурыч: Алкогольгә бәйлелеге булган затларга наркологик медицина ярдәме күрсәтү һәм социаль реабилитацияләү системасын камилләштерү | | | | | | |
| 3.1 | Эчке эшләр бүлегенең һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләрендә исәптә торучы алкогольле һәм спиртлы эчемлекләр кулланучы балигъ булмаганнар өчен, шулай ук әлеге затларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен психиатр-наркологлар тарафыннан консультацияләр оештыру һәм үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Арча ҮХ” ДАССУ (килешү буенча), ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча), Россия ЭЭМ Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 3.2 | Профилактик медицина | 2025-2027 | “Арча ҮХ” ДАССУ | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тикшерүләре уздырганда гражданнар категорияләре арасында алкогольгә бәйлелекнең беренчел симптомнарын ачыклау:<br>- һөнәри эшчәнлеге югары куркыныч чыганагы белән бәйлеләр;<br>- хәрби хезмәткә алынганнар;<br>- урта махсус һәм югары уку йортларына керүчеләр;<br>- балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе юлламасы буенча балигъ булмаганнарның, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның;<br>- пассажирлар һәм йөкләр ташу өчен билгеләнгән автотранспорт чараларын йөртүчеләр | еллар (ел дәвамында) | (килешү буенча), ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча) | | | |
| 3.3 | Исәптә торучы авыруларга диспансеризация үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Арча ҮХ” ДАССУ (килешү буенча) | - | - | - |
| 3.4 | Алкогольгә бәйлелектән интегүче авыруларны диспансер күзәтүе һәм амбулатор дәвалау | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Арча ҮХ” ДАССУ (килешү буенча) | - | - | - |
| 3.5 | “ОУ” да булган авыруларны ай саен күзәтү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Арча ҮХ” ДАССУ (килешү буенча) | - | - | - |
| 3.6 | “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССОда Профилактик, дәвалау һәм тернәкләндерү наркологик ярдәмен алу мөмкинлекләре турында барлык сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният учреждениеләрендә, Эчке эшләр бүлегендә ачык, актуаль, дөрес мәгълүмат урнаштыруны оештыру | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Арча ҮХ” ДАССУ (килешү буенча), “Мәгариф идарәсе” МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Россия ЭЭМның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |
| 3.7 | Наркология бүлегендә дәваланган алкоголизм белән авыручыларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | “Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | - | - | - |

| 4 бурыч: Исерек хәлдә кылынган җинаятьләр санын киметү | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1 | Алкоголь продукциясен чиктән тыш күп кулланучы затлар, шулай ук алкоголь кулланучы балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактика чаралары | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Россия ЭЭМның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), ТР ХЭТИ һәм СЯМның Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча), ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча) | - | - | - |
| 4.2 | Алкогольнең кеше организмына зыянлы йогынтысын, исерек хәлдә кылынган хокук бозулар өчен җаваплылыкны “куркыныч тудыручы төркеме” балигъ булмаган затларга аңлату гамәлләре | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Россия ЭЭМның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), ТР ХЭТИ һәм СЯМның Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча), ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча), “Мәгариф идарәсе” МУ | - | - | - |
| 4.3 | Район территориясендә суррогат спиртлы продукция керүгә, җитештерүгә һәм сатуга юл куймау буенча чаралар күрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Россия ЭЭМның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органы (килешү буенча), АМР БК | - | - | - |
| 4.4 | Балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең массакүләм ял итү урыннарында спиртлы продукция куллануны профилактикалау максатларында комплекслы операцияләр, рейдлар үткәрү | 2025-2027 еллар (ел дәвамында) | Россия ЭЭМның Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), ББЭ һәм ХЯК | - | - | - |

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаны планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм аның үтәлешенә гомуми контрольне Арча муниципаль районы башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул ел саен Программа чараларының максатчан күрсәткечләрен, программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын төгәлләштерә, чараларны үтәү өчен җаваплы субъектлардан программаны үтәүнең барышы турында белешмәләр соратып ала.

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплы төп башкаручылар

Программаның муниципаль заказчысына аның хисап чорыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

Программага үзгәрешләр кертү программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан йә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты йөкләмәләрен билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫ ИНДИКАТОРЛАРЫ

Программа ачык социаль характерда, аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре Татарстан Республикасының Арча муниципаль районы халкы тормышының төрле якларына уңай йогынты ясаячак.

Программа чараларын тулысынча һәм вакытында үтәү халыкның гомуми сәламәтлеген сизелерлек яхшыртачак, районның демографик хәлендә уңай үзгәрешләргә китерәчәк (бигрәк тә хезмәткә сәләтле яшьтәге ир-атлар арасында үлүчеләр саны кимүгә).

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә спиртлы продукция белән кискен агуланулар саны, алкоголь психозлары белән авыручылар саны, алкоголь белән агуланудан үлүчеләр саны, исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны кимүе көтелә.

Муниципаль программа максатлары индикаторлары

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | 2024 ел күрсәткече | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 1 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 2 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 3 елы (соңгы) |
|---|---|---|---|---|---|
| Спиртлы продукция белән кискен агуланулар саны | Кеше | 5 | 4 | 2 | 0 |
| Алкоголь продукциясе белән агулану нәтиҗәсендә халыкның үлү дәрәҗәсе | Кеше | 4 | 3 | 2 | 0 |

## 6 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

Программаны тормышка ашыру өчен Арча муниципаль районы бюджетыннан акча бүлеп бирү каралмаган. Программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү башкаручы учреждениеләрне агымдагы финанслаудан чыгып гамәлгә ашырыла.

*Кулланылган кыскартулар исемлеге:

БК АМР - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты;

“Мәгариф идарәсе” МУ - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе;

Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;

“Мәдәният идарәсе” МУ - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе;

ТР ХЭТИ һәм СЯМның Арча районындагы социаль яклау бүлеге - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;

Арча районы буенча ДКУ "ТР ХЭТИҮ" - Арча районы буенча “Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге” дәүләт казна учреждениесе;

“Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ - “Арча үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

ББЭ һәм ХЯК - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органы - Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенең этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм куллнучылар хокукларын яклау буенча Арча территориаль органы;

Районның шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең башкарма комитетлары;

“Арча ҮКС” МБУ - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча үзәкләштерелгән китапханә системасы” муниципаль бюджет учреждениесе;

УЕШЧ - узган елның шул ук чоры.